две аналитические формы склонения: одна из форм образуется с помощью служебных имен, а вторая формируется с помощью послелогов [8, с. 114-115]. Мысль о том что, служебные слова образуют, аналитическую форму склонения, Н.Оралбаева высказала еще в 1986 году. Идею профессора Н.Оралбаевой об аналитической форме склонения продолжил М.Оразов в своих трудах касающихся вспомогательных и служебных слов. Ученый, исследуя служебные слова, собрав достаточное количество материала, 1997 году опубликовал 2 книги с названием "Служебные слова". Последователь Н.Оралбаевой по исследуемой теме М.Оразов в книге «Служебные слова» высказал мысль о том, «что некоторые из служебных слов необходимо рассматривать в морфологическом аспекте, нужно принять их как один из компонентов аналитического форманта и исследовать как показательческих категорий» [7, с. 5]. Он считает, что служебные имена образуют аналитический формант склонении.

Как известно, ученые рассматривают тюркские языки только как агглютинативные, по их мнению, в них как грамматические, так и лексические значения выражаются агглютинацией, т.е. суффиксацией. Такое рассмотрение полностью искажает сущность и характер тюркских языков, так как в них больше половины лексических, около половины грамматических значений выражается аналитически, т.е. дополнительными словами. Таким образом, в системе морфологии тюркских языков аналитической морфологии принадлежит значительное место, и актуальной задачей тюркологии является ее глубокое и всестороннее исследование.

**Литература**


1. Ахтамова Х.Т. Послеложные аналитические формы в современном узбекском литературном языке. Автореф. дисс. …канд. Наук. – Ташкент, 1981. – 26 с.
2. Большой энциклопедический словарь. Языкознание. – Москва: Науч.изд-во «Большая Российская энциклопедия», 1998. – 685 с.
3. Виноградов В.В. Русский язык. – Москва: Высшая школа, 1972. – 616 с.
4. Ганиев Ф.А. О синтетически и аналитических падежах в татарском языке // Вопросы в тюркологии. – Казань, 1970. – С. 74-84.
5. Ганиев Ф.А. Вопросы морфологии татарского языка. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 81 с.
6. Калыбаева А., Оралбаева Н. Морфемика современного казахского языка. – Алматы, 1986. –189 с..
7. Оразов М. Служебные слова. – Алматы: Наурыз, 1997. – 311 б.
8. Оралбай Н. Морфология современного казахского языка. – Алматы: Арыс, 2007. – 456 с.



**Ахмадгалиева Гузалия Габдрауфовна,**

*к.филол.н., доцент кафедры татарской филологии,*
*Елабужский институт К(П)ФУ,*
*г.Елабуга, Республика Татарстан, Россия,*
*e-mail: guzalia-ahmad@mail.ru*



УДК 81' 373


# Х.ТУФАН ИҖАТЫНДА ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

# ОТРАЖЕНИЕ ТАТАРСКОГО ФОЛЬКЛОРА В ТВОРЧЕСТВЕ Х.ТУФАНА

# THE REFLECTION OF TATAR FOLKLORE IN THE WORKS OF KH.TUFAN


**Аннотация.** В статье представлены некоторые особенности использования Х.Туфаном татарского фольклора в своем творчестве. Будучи поэтом с феноменально чутким и богатым языком, он не просто использует пословицы и поговорки, а выбирает наиболее яркие, самые лучшие образцы народных изречений, творчески их обрабатывает, обогащает и вновь преподносит их народу, носителю языка.



**Ключевые слова:** Х.Туфан, пословица, поговорка, фразеологизм, синоним, фольклор.



**Abstract.** The article introduces us to some peculiarities of using the Tatar folklore by Kh.Tufan. Being the poet of phenomenally sensitive and rich language, he doesn`t simply use proverbs and sayings, but chooses the brightest, the best models of national sayings, creatively them processes, enriches and again represents them to the people, to the native speaker.



**Keywords:** Kh.Tufan, proverb, saying, idiom, synonym, folklore.

Х.Туфан, башка күп кенә шагыйрьләр һәм язучылар белән беррәттән, татар фольклоры, халык авыз иҗаты әсәрләре теле байлыгы алдында баш ия, горурлык хисе тоя.

Х.Туфан үзенең шигырьләрендә мәкаль һәм әйтемнәрдән оста файдаланып кына калмый, халыкның бетмәс-төкәнмәс иҗат чишмәсеннән иң яхшы җәүһәрләрне ала да, аларны иҗади эшкәртеп, баетып, тагы да югарырак баскычка күтәреп, яңадан халыкның үзенә кайтара. Х.Туфан иҗаты өчен фразеологик берәмлекләрне субституция алымы (бер компонентны алыштыру) алымы ярдәмендә трансформацияләү дә чит түгел. Яңа элементлар буларак ул синонимнардан яки мәгънәләре охшаш булган сүзләрдән файдалана. Алда әйтеп кителгән субституция алымы ярдәмендә шагыйрь кайбер мәкаль әйтемнәрне үзгәртеп куллана. Мәсәлән:

Тарихның шушы исемгә
Сылаган ялалары
Төзәлмәс яра шикелле
Бүген дә яна әле.

(«Монголын, һунын даланың»)

Бер әйләндем, өч әйләндем,
Биш әйләндем Җир шарын:
Өлешемә төшкән көмеш –
Мәңгелегем дигән кешем
Син икәнсең бит, җаным.

(«Бер әйләндем, өч әйләндем»)

Х.Туфан традицион яла ягу, өлешеңә тигән көмеш фразеологизмнарыннан файдаланмыйча, аларны яла сылау, өлешемә төшкән көмеш дип куллана. Болай итү аңа үз фикерләрен укучыга үтемлерәк, күңелендә сакланып калырдай итеп бирергә ярдәм итә.

Фразеологик берәмлекнең үзгәрүе мәсьәләсе илебез һәм чит ил галимнәренең игътибарын үзенә җәлеп итә. Н.Н. Амосова, Л.К. Бәйрәмова фразеологик берәмлекнең тышкы формасы үзгәрүе мәгънә үзгәрүенә китермәскә дә, тик шул ук алымнар ярдәмендә мәгънә үзгәрүенә китерергә дә мөмкин, дип саныйлар [1, б. 3-11].

…Җиде төндә җиде юл чатыннан
«Баксам әгәр Җидегәнеңә,
«Җиде үлчә – бер кис!» дигәннәрең
Иңде минем күңелләремә.

(«Җиделәр»)

Салам кыстыручы сафташларың
Үзең белән… китеп бардылар.
Күпме югалтулар! Җаннар түгел,
Сине хәтта ташлар каргыйлар…

(«Ильич синең төп сыйфатны андук»)

Анда йөри,
«Җиде үлчә – бер кис» дигәнедәй,
Сугым кебек ялкау трамвай.
Анда көтү малай
Һәрбер килгәненә
Маэмай кебек һаулап торалар.

(«Зәңгәр бүре»)

Безнең якта үзе булмаса да
Ишәк дигән мәшһүр хайванның,
«Иртәгене – ишәк кайгырта», – дип
Йөри торган төре бар аның.

(«Ишәк турында»)

Әлеге мисалларда фразеологик берәмлекләрнең тулы булмаган формасы кулланылган. Бу алым эллипсис дип атала, фразеологимнар арасында киң кулланылыш тапмаса да (фразеологик берәмлекнең структур яктан таркалмавы аркасында), шагыйрь, күргәнебезчә, бу алымны уңышлы файдалана. Мисаллардан күренгәнчә, халык телендә йөргән җиде кат үлчә, бер кат кис мәкаленең кат сүзе, салпы якка салам кыстыру мәкаленең салпы якка өлеше, иртәгесе өчен ишәк кайгырта гыйбарәсенең өчен бәйлеге төшерелеп калдырылган. Моңа карамастан, шигырьнең матурлыгы югалмый, бәлки киресенчә, ниндидер үзенә күрә бер образлылык, халыкчанлык сизелеп тора, автор фразаны төрләндереп, аңа динамика өсти, аерым бер контекстуаль мәгънә бирә.

Әмма шагыйрь бу алымнан кала, халык мәкальләрен куллануның яңа ысулларын таба, үзен укучыларга новатор-шагыйрь буларак тәкъдим итә. Мәсәлән:

Безнең

Бу аяклар элек
Юрганына карап сузылса,
Безнең юрган инде
Аякларга карап сырыла.

(«Урал эскизлары»)

Монда татар халык мәкаленең ниндидер төсмере генә калган, ул Х.Туфан тарафыннан нык кына үзгәртелгән. Һәм иң кызыклысы шунда – Х.Туфан үзе яңа әйтем уйлап тапкан: аягына карап юрган сыру. Һәм бу әйтем аягыңны юрганыңа карап суз дигән татар халык мәкаленең капма-каршы мәгънәсен белдерә. Күренеп тора, автор иң элек мәкаль һәм әйтемнәрнең философик (гомумтормыш) мәгънәсенә игътибар итә. Сүз уйнату атамасын йөрткән бу алым нигезендә фразеологик берәмлекне ике яклап актуальләштерү ята. Билгеле, әйдәп баручы функциясен актуальләштерүче коррелятлар − фразеологик берәмлек белән мөнәсәбәттәш булган контекст компонентлары башкара. Бу алымнан авторның оста файдалануын түбәндәге мисалларда да күзәтеп була:

«Туганга тугры ярамый», −
Дисә дә татар элек,
Бүгенге чорда, туганга
Тугры да батар кебек.

(«Серләшик әле, агаем»)

Серләшик әле, агаем,
Үзләрчә итеп кенә,
Киленгә дигән киңәшне
Тик кызга биреп кенә…

(«Серләшик әле, агаем»)

Күренеп тора, кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла; туры әйткән туганына ярамаган мәкальләренең бары кайбер компонентлары (килен, кыз; туган, туры, ярамый) гына сакланып калган, тик шулай да мәкальнең мәгънәсе югалмаган, ул бары автор интерпретациясендә бирелгән. Әйтемгә салынган мәгънәне автор үз сүзләре, шигырь тукымасына ята алырдай рифмага салып биргән. Беренче карашка, бу фразеологик берәмлек түгел дә кебек, тик шулай да бу сүзләр тезмәсенә алда әйтеп үтелгән мәкаль мәгънәсе, көчерелмә мәгънә, образлылык хас.

Мәкальләрдән иҗади файдалануның тагы бер мисалы итеп түбәндәге юлларны китерергә мөмкин:

Ана сөте белән кермәгәнне
Тормыш үзе кертә
Күңелгә.
Ана сөте белән кергәнне дә
Үзгәртәләр безнең гомерләр.

(«Башлана башлады»)

Автор ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән керми дигән татар халык мәкален алган да, аңа бөтенләй башка төрле мәгънә салган, капма-каршы мәгънәле фразеологик әйтелмә барлыкка китергән.

Фразеологик әйтелмәләрнең экспрессивлыгын көчәйтү өчен, аның мәгънә төсмерләрен үзгәртү өчен кулланылган стилистик алымнар фразеологизмның семантик төзелешен (структурасын) окказиональ төрләнүенә китерә. Фразеологизмнарны төрләндерү ысулларының системалылыгы һәм нормативлыгы Х.Туфан әсәрләрендә индивидуаль, иҗади тормышка ашыру осталыгы, стилистик, сурәтләү функцияләре белән яраша.

### Литература


1. Байрамова Л.К. Тождество фразеологизмов в зеркале трансформаций и корреляций // Проблема тождества фразеологических единиц. − Челябинск, 1990. − С. 3-11.
2. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989, 1990.
3. Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистика һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.